РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
Алькеевского
муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки
муниципаль районы
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Адрес: 422870, РТ, с. Базарные Матаки,
ул. Крайнова, 56
тел: 8 (84346) 2-17-60

Адресы: 422870, РТ, Базарлы Матак авылы,
Крайнов ур., 56
факс: 8 (84346) 2-17-60

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАРЫ**

2021елның 17 февраля 52 №

Әлки муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 13 сентябрендәге "Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында" 372 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге "Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 880 номерлы карары нигезенләнеп, Әлки муниципаль районы КАРАР БИРӘ:

1. «Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2018елның 13 сентябрендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 372 номерлы карары белән расланган җир эшләрен җитештерүгә ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 28 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш)»

2 бүлекнең 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш)»;

3 бүлекнең исеме түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең ерак урнашкан эш урыннарында, күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре»

3.4.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3 пунктча өстәргә:

«3) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә (авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш)».

2. «Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 13 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыруга шартнамәләр төзү» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 372 нче карары белән расланган 71 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.6.2 пунктын түбәндәге эчтәлекле 5),6) абзацлар белән тулыландырырга:

«5) элек төзелгән килешү буенча җир участогыннан фактта файдалану өчен түләү буенча бурычлар булу турында белешмәләр;

6) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында мәгълүматлар-Россия ФСХ»

2.8 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4),5) пунктчалар белән тулыландырырга:

4) килешүнең гамәлдә булу чорында аренда түләве (шул исәптән пеня) буенча бурыч булу, шулай ук стационар булмаган сәүдә объекты урнаштыру өчен элек төзелгән җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе буенча җир кишәрлегеннән фактта файдалануга түләү буенча бурыч булу;

5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»

3. «Әлки муниципаль районы башкарма комитетының 2018 елның 13 сентябрендәге «Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 372 карары белән расланган 45 нче кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлекнең 2.6 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5) абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә-Россия ФСХ.»

2 бүлекнең 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5) пунктчасын өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу.»

2.Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми портал"ында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Интернет - телекоммуникация челтәренең Әлки муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлки муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Әлки муниципаль районы
Башкарма комитет җитәкчесе: И. В.Юсупов